Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын әзерләү турында

Россия Федерациясенең 2004 елның 29 декабрендәге 190-ФЗ номерлы Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль закон, «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын әзерләүгә керешергә.
2. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясен (1 нче кушымта) төзергә.
3. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясе турында нигезләмәне (2 нче кушымта) расларга.
4. Шәһәр төзелешен зоналаштыру этапларын билгеләргә (3 нче кушымта).
5. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын әзерләү эшләрен башкару тәртибен һәм срокларын билгеләргә (4 нче кушымта).
5. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын әзерләү буенча кызыксынучы затларның тәкъдимнәрен комиссиягә җибәрү тәртибен (5 нче кушымта) билгеләргә.
6. Әлеге карарны «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында ( http:zelenodolsk.tatarstan.ru ) урнаштырырга .

Җитәкче урынбасары Д.В. Лулаков

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карарына карата 1 нче кушымта
___________ №_________

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясе составы**

| № т/б | Фамилиясе, исеме, атасының исеме | Вазифасы |
|---|---|---|
| 1. | Старостин А. В. | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары-Комиссия рәисе; |
| 2. | Сергеев П.Н. | «Зеленодольск муниципаль районының архитектура һәм шәһәр төзелеше сәясәте идарәсе » МБУ җитәкчесе-Комиссия рәисе урынбасары; |
| 3. | Нургалиева Э. Ә. | Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының юридик бүлеге начальнигы (килешү буенча) – комиссия әгъзасы; |
| 4. | Соловьев А.В. | Зеленодольск шәһәренең 2 нче сайлау округыннан депутат (килешү буенча) -комиссия әгъзасы; |
| 5. | Макеев В.Б. | Зеленодольск шәһәренең 4 нче сайлау округыннан депутат (килешү буенча) - комиссия әгъзасы; |
| 6. | Савельев С.Н. | Зеленодольск шәһәренең 6 нчы сайлау округыннан депутат (килешү буенча) - комиссия әгъзасы; |
| 7. | Алексахина А. Ю. | «Зеленодольск муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре МУ җитәкчесепалатасы» МУ җитәкчесе - комиссия әгъзасы; |

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карарына карата
2 нче кушымта
___________ №_________

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясе турында нигезләмә**

## 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә (алга таба – Зеленодольск шәһәре)җирдән файдалануны һәм төзелеш алып баруны җайга салу системасының эзлекле камилләшүен һәм нәтиҗәле эшләвен тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясе (алга таба - Комиссия) төзелә.

Комиссия Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карары нигезендә төзелә.

Комиссия даими эшләүче һәм үз эшчәнлеген әлеге Нигезләмәгә таянып һәм 2004 елның 29 декабрендәге 190-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә гамәлгә ашыра.

## 2. КОМИССИЯ СОСТАВЫ

2.1. Комиссия составы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән раслана.

2.2. Комиссия рәисе урында булмаганда, аның вазифаларын Комиссия рәисе урынбасары башкара.

## 3. КОМИССИЯ КОМПЕТЕНЦИЯСЕ

3.1. Комиссия компетенциясенә түбәндәгеләр керә:

3.1. Җирдән файдалануны һәм төзелеш алып баруны җайга салу системасын эзлекле камилләштерү процессын оештыру, шул исәптән җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр проектын эшләүне, ә алга таба аларны гамәлгә ашыру;

3.2. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын эшләүгә бәйле рәвештә гражданнарның һәм юридик затларның тәкъдимнәрен карау;

3.3. Гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча бәяләмә чыгару, тәкъдимнәр әзерләү һәм аларны Россия Федерациясе шәһәр төзелеше кодексы нигезендә Зеленодольск муниципаль районының Зеленодольск шәһәре Мэрына җибәрү.

## 4. КОМИССИЯ ЭШЧӘНЛЕГЕ ТӘРТИБЕ

4.1. Комиссия кирәк булган саен җыела, ләкин аена бер тапкырдан да ким түгел.

4.2. Комиссия утырышы, әгәр Комиссия әгъзаларының билгеләнгән саныннан кимендә өчтән икесе катнашса, хокуклы дип санала.

4.3. Комиссия карары Комиссия әгъзаларыннан гади күпчелек тавыш белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, рәиснең тавышы хәлиткеч булып тора.

4.4. Гражданнарның һәм юридик затларның тәкъдимнәре Комиссия рәисе исеменә җибәрелә. Комиссия рәисе аларны Комиссия утырышларында ике атна дәвамында карап тикшерүне тәэмин итә.

4.5. Күрсәтелгән 4.4 пунктта каралган тәкъдимнәрне карау нәтиҗәләре буенча карар кабул ителә, ул беркетмәдә чагыла.

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карарына карата 3 нче кушымта
___________ №_________

**Җирлек территориясенә карата шәһәр төзелешен зоналаштыру этаплары**

1. Торак зоналар.
2. Иҗтимагый-эшлекле зоналар.
3. Җитештерү һәм коммуналь зоналар.
4. Инженерлык-транспорт инфраструктурасы зонасы.
5. Авыл хуҗалыгы кулланышындагы зоналар.
6. Рекреацион билгеләнештәге зоналар.
7. Махсус билгеләнештәге зоналар.
8. Шәһәр төзелеше регламентлары кагылмый торган җирләр билгеләнми.

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карарына карата 4 нче кушымта
___________ №_________

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын әзерләү эшләре һәм сроклары**

| № т/б | Эшләрнең атамасы | Үткәрү |
|---|---|---|
| 1 | Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын әзерләү турында карар кабул итү турындагы хәбәрне бастырып чыгару | 21.10.2019 |
| 2 | Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын Комиссия тарафыннан әзерләү | 15.10.2019 |
| 3 | Комиссия тарафыннан тәкъдим ителгән Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын техник регламентларның таләпләренә, Зеленодольск шәһәренең Генераль планына туры килү-килмәү буенча тикшерү | 15.10.2019 |
| 4 | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектының техник регламентларның таләпләренә, Зеленодольск шәһәренең Генераль планына туры килүе яки туры килмәве турында бәяләмәсен әзерләү | 15.10.2019 |
| 5 | Зеленодольск шәһәре Мэры тарафыннан Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү турында карар кабул итү | 16.10.2019 |
| 6 | Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелешләр алып бару кагыйдәләре буенча гавами тыңлаулар үткәрү, гавами тыңлаулар беркетмәләрен әзерләү, гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында йомгак ясау | 30.10.2019-3.12.2019 |
| 7 | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенә Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын гавами тыңлаулар тәмамланганнан соң, кушымталар белән гавами тыңлаулар беркетмәләрен, гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәне тапшыру | 06.12.2019 |

| | | |
|---|---|---|
| 8. | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын Зеленодольск шәһәре Советына җибәрү турында карар кабул итү | 06.12.2019 |

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карарына карата 5 нче кушымта
__________ №________

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын әзерләү буенча кызыксынучы затларның тәкъдимнәрен комиссиягә җибәрү тәртибе**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектына тәкъдимнәр һәм күрсәтмәләр кертелә:

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектына тәкъдимнәр һәм күрсәтмәләр язма рәвештә әлеге тәртипкә кушымта нигезендә кертелә.

Катнашучыларның тәкъдимнәр һәм күрсәтмәләр кертү формасы:

- гавами тыңлауларда катнашучыларның җыелышын яисә җыелышларын уздыру барышында язма яисә телдән ;

- Комиссиягә Зеленодольск шәһәре, Ленин урамы, 41а йорты адресы буенча 211 каб. язмача

- гавами тыңлаулар каралырга тиешле проект экспозициясен исәп кенәгәсендә(журналда) килүчеләрне исәпкә алу юлы белән.

Тәкъдимнәр һәм күрсәтмәләр «Зеленодольск муниципаль районының архитектура һәм шәһәр төзелеше сәясәте идарәсе» МБУ белгечләре тарафыннан язма рәвештә, кирәк вакытта схема һәм башка материаллар белән кабул ителә.

Тәкъдимнәр һәм күрсәтмәләр бертөрле укырга тиеш. Җибәрелә торган материалларда «2019 елның 3 декабрендә 16.00 сәгатьтә Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар өчен» тамгасы булырга тиеш.

Аноним тәкъдимнәр һәм күрсәтмәләр кабул ителми.

Гавами тыңлауларда катнашучылар идентификация максатларында үзләре турында белешмәләр (фамилия, исем, атасының исеме (булган очракта), туу датасы, яшәү (теркәү) урыны адресы - физик затлар өчен; исеме, төп дәүләт теркәве номеры, урнашу урыны һәм адресы - юридик затлар өчен) тапшыралар, мондый белешмәләрне раслый торган документларны кушып.

Тиешле җир кишәрлекләренә һәм (яисә) аларда урнашкан капиталь төзелеш объектларына һәм (яисә) күрсәтелгән капиталь төзелеш объектларының бер өлеше булган урыннарга хокуклы булган гавами тыңлауларда катнашучылар, шулай ук мондый җир кишәрлекләре, капиталь төзелеш объектлары, күрсәтелгән

капиталь төзелеш объектларының бер өлеше булган биналар, Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрыннан һәм аларның мондый җир кишәрлекләренә, капиталь төзелеш объектларына, капиталь төзелеш объектларының бер өлеше булган биналарга хокукларын билгели торган яисә раслый торган башка документлар турында белешмәләр тапшыралар.

Тәкъдимнәр һәм күрсәтмәләр катнашучының гавами тыңлауларда дөрес булмаган белешмәләр бирү фактын ачыклаган очракта каралмый.

Катнашучыларның тәкъдимнәр һәм күрсәтмәләр кертү вакыты: 2019 елның 3 декабренә кадәр.

Гражданнарның
тәкъдимнәрен исәпкә алу
тәртибенә кушымта

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектына тәкъдимнәр һәм күрсәтмәләр**

| Фикер алышуга чыгарылган сораулар | | Экспертларның һәм катнашучыларның тәкъдимнәре күрсәтмәләре | | Тәкъдимнәр (рекомендаци кертелде (хупланды) | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|
| № т/б | Сорауның формулировкасы проект исеме . | № т/б | җөмлә тексты | Ф.И.О., туу датасы, яшәү урыны адресы (теркәлү) - физик затлар өчен; исеме, төп дәүләт теркәве номеры, урнашу урыны һәм адресы - юридик затлар өчен | |
| 1 | | 1.1 | | | |
| | | 1.2 | | | |
| 2 | | 2.1 | | | |
| 3 | | 2.2<br>3.1<br>3.2 | | | |

«Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә җирдән файдалану һәм төзелешләр алып бару кагыйдәләре проектына карата тәкъдимнәрне һәм күрсәтмәләрне карау максатларында минем шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризамын (кушымтада бирелә)

______________________________
(Имза Ф.И.Ат.и.)

Кушымта
Гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу
тәртибенә

___________________________________
___________________________________
___________________________________,
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган
очракта))
_____________________________яшәүче
_________________________________,
(яшәү урынының адресы)
телефон номеры ______________________

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык бирү турында
ГАРИЗА

Мин,
______________________________________________________________________,
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)
шәхесне раслаучы документ, _______________________________________________
сериясе ________ № ______________, бирелде
_____________________________________________________________________________
_____________________________________________________________бирелү датасы,
"Шәхси мәгълүматлар турында" 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы нигезендә Зеленодольск шәһәре Советына минем шәхси мәгълүматларымны, шулай ук башка мәгълүматларны эшкәртүгә һәм куллануга ризалыгымны бирәм.

Мин шәхси мәгълүматларны бары тик Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектына карата тәкъдимнәрне һәм күрсәтмәләрне исәпкә алу максатларында файдалануга ризалык бирәм.

Үзем турында түбәндәге мәгълүматларны саклауга, эшкәртүгә һәм тапшыруга ризалык бирәм:

1. Фамилиям, исемем, әтинең исеме, туган көнем.

2. Теркәлү, вакытлыча теркәү, фактта яшәү адресы, телефоннар.

Әлеге килешү, мин югарыда күрсәтелгән максатларга ирешү өчен кирәк булган персональ мәгълүматларга карата гамәлләрне гамәлгә ашыруга бирелә, шул исәптән (чикләүсез) җыю, системалаштыру, саклау, туплау, төгәлләштерү (яңарту, үзгәртү), өченче затларга мәгълүмат алмашу буенча гамәлләр башкару өчен файдалану, шәхси мәгълүматларны бетерү, блоклау, шулай ук Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарында каралган теләсә нинди гамәлләрне тормышка ашыруга.

Әлеге ризалыкның гамәлдә булу срогы чикләнмәгән. Әлеге ризалык теләсә кайсы вакытта минем язма гаризам буенча кире алынырга мөмкин.

Мин шуны раслыйм, әлеге ризалыгымны биргәндә, мин үз ихтыярым һәм үз мәнфәгатьләрем буенча эш итәм.

"____" ___________ 201____ел ______________ /______________/

*Имза* *Имзаның аңлатмасы*